**Факил САФИН,**
*язучы, 1998-2003 елларда «Ләйсән»*
*әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе*

## ЗАМАН, ВАКЫТ ҺӘМ ҮЗЕБЕЗ ТУРЫНДА

...Чаллы зур тарихлы, борынгы төбәк. Анда әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр моңарчы да аз булмагандыр. Әмма төбәкнең рухи мирасы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, әле бу эшкә яңа керешеп кенә киләбез. Ышанам, бу гүзәл төбәктә яшәп, фани дөньядан бакыена күчкән гаҗәп талантларның күп әсәрләре вакыт тузаны астында күмелеп, якты дөньяга чыгасы сәгатьләрен көтеп ята торганнардыр...

Чаллыда зур төзелешләр башлангач (башта Чаллы янында ук Түбән Кама ГЭСы плотинасы төзелә башлый, аннан атаклы КАМАЗ төзелеше...), Чаллыга төрле төбәкләрдән яшьләр агыла. Араларында иҗат белән шөгыльләнүчәләр дә шактый. Алар өлгер, матур омтылышлы, дөньяны, һич тә булмаса үзләрен үзгәртергә ант эчкән, хыялый җәмгыять төзергә алынган фидакярләр иде. Әдәби мохит түгәрәк кысаларына гына сыешмый башлый, аның нигезендә яңа әдәби иҗат берләшмәсе төзелә. Җитмешенче еллар башында телгә «Ләйсән» исеме килеп керә. Аның утырышларына прозаик, шагыйрь, журналистлардан тыш, талантлы музыкантлар, Халык театры артистлары, җырчылар, рәссамнар да актив катнашалар, ул, Чаллы каласын ныклап урыслашудан саклап, татар рухиятен тотып торучы, алга этәрүче төп, бердәнбер көчкә әверелә.

Җитмешенче елларның уртасыннан башлап Чаллыга профессиональ саналган, ягъни, язучылар берлеге әгъзалары туплана башлый.

1980 елны, Чаллы язучыларның туктаусыз тынгысызлап торуы, шәһәр җитәкчесе Рәис Беляевның булышлыгы һәм ул чактагы Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе Гариф Ахунов ярдәме белән, Чаллы Язучылар оешмасы төзелде. Үзбашка оешма буларак ул соңгы чорларга кадәр яшәп килде. Хәзер оешмабыз Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге дип атала.

*Әдәби Чаллы / Төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова. –*
*Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б.336-339.*